**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**

**(IV чакырылыш)**

IV чакырылышның XVIII утырышы

**КАРАРЫ**

«22» апрель 2024 ел № 9 Урыссу ш.т.б.

Татарстан Республикасы Ютазы районы Советының 2021 елның 29 октябрендәге 82 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәгә өстәмәләр кертү хакында

Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Торак кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»гы 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ санлы Федераль закон, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр хокукларын яклау турында»гы 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәгә» Татарстан Республикасы Ютазы районы Прокуратурасының 2024 елның 15 февралендәге 02-08-01/3 санлы протесты белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2021 елның 29 октябрендәге 82 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турындагы Нигезләмәгә түбәндәге өстәмәләр кертергә:

1.1. Түбәндәге эчтәлектәге 8 маддә белән тулыландырырга:

**«8. Муниципаль контроль кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу риск индикаторлары исемлеге**

1) Муниципаль торак фондының торак бинालары булган күпфатирлы йортта, көн тәртибендәге шундый ук мәсьәләләр буенча карарлар булган,

милекчеләрнең гомуми җыелышының ике һәм аннан да күбрәк беркетмәсен өч ай рәттән муниципаль торак контроле органына кертү;

2) Бердәм диспетчерлык хезмәте мәгълүматлары буенча, контрольдә тотыла торган зат идарәсендә күп фатирлы йортта гомуми милектәге җитешсезлекләрне бетерү буенча эшләр башкару өчен атнага биштән артык ремонт бригадасы чакырыла;

3) Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү документларында күпфатирлы йорт милекчеләренең гомуми мөлкәтен файдаланганда һәм тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләү күләмен алдагы шундый ук исәп-хисап чоры белән чагыштырганда 50% тан артык арттыру турында белешмәләрне ачыклау.».

2. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2021 елның 29 октябрендәге 82 санлы карары белән расланган нигезләмәгә өстәмәләр кертү хакында»гы 2023 елның 31 октябрендәге 55 санлы карары үз көчен югалткан дип танырга

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендәге махсус мәгълүмати стендларда игълан итәргә, http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталы «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының законлылык, регламент һәм җирлекләр советлары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Башлыгы
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин